ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.03.2023 г. Казань № 13-12/тп-2023

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2023 елга тоташтырыла торган җылылык басымы егәрлегенең бер берәмлегенә исәпләгәндә «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте Чаллы җылылык челтәрләре филиалының җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен түләү билгеләү турында» 14.12.2022 №750-285/тп-2022 карары кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы, «Җылылык белән тәэмин итү системаларына тоташтыру (технологик ялгау) буенча хезмәтләрдән дискриминацияле булмаган нигездә файдалану кагыйдәләрен дә кертеп, җылылык белән тәэмин итү системаларына тоташтыру (технологик ялгау) кагыйдәләрен, Җылылык энергиясен, җылылык чыганагын тапшыру хезмәтләреннән дискриминацияле булмаган нигездә файдалану кагыйдәләрен раслау, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләрне үзгәртү һәм көчләрен югалткан дип тану турында» 2021 елның 30 ноябрендәге 2115 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 2023 елның 1 мартындагы 6-ПР номерлы беркетмәсе

нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2023 елга тоташтырыла торган җылылык басымы егәрлегенең бер берәмлегенә исәпләгәндә «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте Чаллы җылылык челтәрләре филиалының җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен түләү билгеләү турында» 14.12.2022 № 750-285/тп-2022 карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2.1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.2.1.2 | 251-400 мм | 2 835,350»; |

2.2.1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.2.1.3 | 401-550 мм | 2 818,630»; |

2.2.2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.2.2.1 | 250 мм кадәр | 6 286,833». |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев